**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 8 Закона Республики Татарстан «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
29 ноября 2017 года

**Статья 1**

Внести в статью 8 Закона Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 3 (I часть); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I часть); 2011, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I часть), № 12 (II часть); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I) изменения, дополнив ее пунктами 6 – 9 следующего содержания:

«6. Встречи депутата с избирателями проводятся в помещениях, специально отведенных местах, а также на внутридворовых территориях при условии, что их проведение не повлечет за собой нарушение функционирования объектов жизнеобеспечения, транспортной или социальной инфраструктуры, связи, создание помех движению пешеходов и (или) транспортных средств либо доступу граждан к жилым помещениям или объектам транспортной или социальной инфраструктуры. Уведомление уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан по проведению собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан или органа местного самоуправления соответствующего муниципального образования о таких встречах не требуется. При этом депутат вправе предварительно проинформировать указанные органы о дате и времени их проведения.

7. Уполномоченный орган исполнительной власти Республики Татарстан по проведению собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан (орган местного самоуправления соответствующего муниципального образования) определяет специально отведенные места для проведения

встреч депутатов с избирателями, а также перечень помещений, предоставляемых органами исполнительной власти Республики Татарстан (органами местного самоуправления соответствующего муниципального образования) для проведения встреч депутатов с избирателями, и порядок их предоставления.

Определение уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан по проведению собраний, митингов, демонстраций, шествий и пикетирований в Республике Татарстан перечня помещений, предоставляемых для проведения встреч депутатов с избирателями, осуществляется по представлению органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области имущественных отношений.

8. Встречи депутата с избирателями в форме публичного мероприятия проводятся в соответствии с законодательством Российской Федерации о собраниях, митингах, демонстрациях, шествиях и пикетированиях.

9. Воспрепятствование организации или проведению встреч депутата с избирателями в форме публичного мероприятия, определяемого законодательством Российской Федерации о собраниях, митингах, демонстрациях, шествиях и пикетированиях, влечет за собой административную ответственность в соответствии с законодательством Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
14 декабря 2017 года
№ 91-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында” Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында” 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 6 – 9 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

“6. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары, аларны үткәрү яшәеш тәэмин итү, транспорт яисә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшчәнлеген бозуга, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә йә гражданнарның торак урыннарга яисә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүләренә комачаулык тудыруга китермәү шарты белән, биналарда, махсус каралган урыннарда, шулай ук ишек алды эчендәге территорияләрдә үткәрелә. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрү буенча вәкаләтле органына яисә тиешле муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органына мондый очрашулар турында хәбәр итү таләп ителми. Монда депутат күрсәтелгән органнарга аларны үткәрү датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

7. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрү буенча вәкаләтле органы (тиешле муниципаль берәмлекнең җирле

үзидарә органы) депутатларга сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен махсус каралган урыннарны, шулай ук депутатларга сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары (тиешле муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары) тарафыннан бирелә торган биналар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгели.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар үткәрү буенча вәкаләтле органы тарафыннан депутатларга сайлаучылар белән очрашулар үткәрү өчен бирелә торган биналар исемлеген билгеләү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тәкъдиме белән гамәлгә ашырыла.

8. Депутатның сайлаучылар белән гавами чара рәвешендәге очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелә.

9. Депутатның сайлаучылар белән җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә торган гавами чара рәвешендәге очрашуларын оештыруга яисә үткәрүгә комачаулык итү Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка китерә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 14 декабрь
№ 91-ТРЗ